ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ИСПОЛКОМ БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а”

тел.+7(84396) 2-64 -66
тел./факс +7(84396) 2-64-66
эл.почта Berk.Cmn@tatar.ru

423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ, УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»

**20.06. 2024 ел** **№ 10**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 26 апрелендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 18 апрелендәге 03-12/2677 номерлы карары белән, авыл җирлеге баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәт хакын түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 26 апрелендәге 37 номерлы карарына (2022 елның 16 ноябрендәге 18а номерлы, 2023 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмә»нең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның вазыйфаи окладны 23700,00 сум (Егерме өч мең җиде йөз сум) күләмендә билгеләнә».

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме сакланган очракта һәм шул ук квалификация эшләрен башкарганда, әлеге карар нигезендә билгеләнә

торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме 2024 елның 30 июненә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесе Р.М.Сибгатуллин